**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**С О В Е Т**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 15** **2015 елның 8 апреле**

**Түбән Кама муниципаль районы Советының 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы һәм финанс сәясәте турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2007 елның 3 августындагы 35 номерлы, 2013 елның 18 декабрендәге 43 карарлары редакциясендә)**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Түбән Кама муниципаль районы Советына кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә

**КАРАР КЫЛА:**

«Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет-финанс сәясәте нигезләмәләрен раслау турында» 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Советының («Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет-финанс сәясәте буенча нигезләмәләрне раслау турында» 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә (Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1.14 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

- “Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары, керемнәре чыганаклары исемлеге нигезендә аларга беркетелгән керемнәр чыганаклары буенча бюджет керемнәре чыганаклары реестрын алып бара";

1.2.18 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Муниципаль контрактлар муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм

расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу план-графигы нигезендә төзелә һәм, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнә»;

1.3.20 статьяның 6 пунктында «квартал саен һәм еллык хисапларга" сүзләрен «еллык хисапка" сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 30 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә: "**30. Бюджет проекты белән бер үк вакытта тапшырыла торган документлар һәм материаллар**

Район Советына бюджет турындагы карар проекты белән бер үк вакытта:

- бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

- агымдагы финанс елының узган чорында районның социаль-икътисади үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм агымдагы финанс елында районның социаль-икътисади үсешенең көтелгән нәтиҗәләре тапшырыла;

- районның социаль-икътисади үсеше фаразы;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына район берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның, дефицитның (профицитның) гомуми күләме я уртача сроклы финанс планы расланган төп характеристикалар фаразы (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның, дефицитның (профицитның) күләме);

- бюджет проектына аңлатма язуы;

- бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәп-хисаплар;

- чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына) киләсе елның 1 гыйнварена муниципаль эчке бурычның иң югары чиге һәм (яисә) чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварена дәүләт тышкы бурычының иң югары чиге;

- агымдагы финанс елына бюджетның көтелүче үтәлешен бәяләү;

- күрсәтелгән бюджет сметаларына карата район Советы, контроль-хисап палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән бюджет сметаларының бюджет һәм финанс департаменты белән каршылыклар барлыкка килгән очракта тапшырыла торган проектлары;

- башка документлар һәм материаллар».

1.5. 43 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә **«43. Бюджет системасы бюджетлары үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү нигезләре Бюджет үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү**:

- бюджет акчалары белән операцияләрне исәпкә алу Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Федераль казначылык органнарына Россия

Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә һәр бюджет өчен аерым ачылган бюджетларның бердәм счетларында гамәлгә ашырыла;

- бюджетларның бердәм счетларында акча белән идарә итүне бюджет һәм финанслар департаменты Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары нормативларына таянып башкара;

- бюджеттан касса түләүләре Федераль казначылык органына тапшырылган түләү документлары нигезендә, аларны тапшыру чираты тәртибендә һәм бюджетның бердәм счетында калган акчаларның факттагы булуы чикләрендә Федераль казначылык органы тарафыннан гамәлгә ашырыла;

- бюджетка касса керемнәре һәм бюджеттан касса түләүләре буенча барлык операцияләр Федераль казначылык органы тарафыннан Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодлары буенча үткәрелә һәм исәпкә алына;

- Федераль казначылык органнары бюджет һәм финанслар Департаментына район бюджетын үтәү буенча касса операцияләре, шулай ук консолидацияләнгән бюджетка керүче башка бюджетларны үтәү буенча касса операцияләре турында мәгълүмат тапшыралар;

- Федераль казначылык органнары федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә шәхси счетлары Федераль казначылык органнарында, бюджет һәм финанс департаментында ачылган оешмаларның акчалата акчалары белән тәэмин итүне оештыралар.»

1.6. 44 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «5. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварена кулланылмаган, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р.Долотказина